**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**21.11.2023 ел** **№ 117**

**Зәй м униципаль районы Югары Налим авыл җ ирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 113 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендәмуниципальхезмәттурында» Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы К одексының 10 статьясына үзгәрешләр ке ртү ха кында» Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

карар итте:

Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 113 нчы номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 9 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) 11 нче өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 нче өлеш үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 нче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“20. Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чины бирү турында карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чины бирү вәкаләте булган органга яки җирле үзидарә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән сыйныф чины бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер ай эчендә кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Совет рәисе Л.И. Сибгатуллин